**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кәминкә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең **Түбән Кәминкә** торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**30 октябрь 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 30 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2025 елда Түбән Кәминкә авыл җирлегенең Түбән Кәминкә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булганнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Түбән Кәминкә торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- **электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Түбән Кәминкә торак пунктында урам яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру)**;**
- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (Түбән Кәминкә торак пунктындагы суүткәргеч челтәре скважиналарына насослар сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 292 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 157 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының **138** катнашучысы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен **19** катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең **Түбән Кәминкә** торак пунктында халык җыены **булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын** дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2025 елда Түбән Кәминкә авыл җирлегенең Түбән Кәминкә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булганнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Түбән Кәминкә торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

**- электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Түбән Кәминкә торак пунктында урам яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру)**;**

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (Түбән Кәминкә торак пунктындагы суүткәргеч челтәре скважиналарына насослар сатып алу)

кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: **Түбән Кәминкә** авылы, Үзәк урамы, 49, Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы

Түбән Кәминкә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Халиков